| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан<br>Совет Кавзияковского<br>сельского поселения<br>Сармановского<br>муниципального района** | **Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районы Кэужияк авыл<br>җирлеге советы** |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 ел 22 ноябрь Кәүҗияк авылы № 24

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге составына керүче Кәүҗияк авылында 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге советы карар итте:

1. 2020 елда Кәүҗияк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән гражданнардан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга:
- Кәүҗияк авылында Сабантуй үткәрү территориясен койма белән әйләндереп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм эш өчен түләү ;
- Кәүҗияк авылына урам яктырткычлары сатып алу;
- Кәүҗияк авылы мәдәният йорты территориясен койма белән әйләндереп алу һәм эш өчен түләү ;
- газ 3512 махсуслаштырылган техникасын тоту(йөк үзбушаткычы): дизель ягулык- майлау, запас частьләр сатып алу;
- Кәүҗияк авылы территориясендә үлән чабу;
- Кәүҗияк авылы һәйкәлен тышлау буенча төзелеш материаллары сатып алу һәм эшләр өчен түләү ;
- Кәүҗияк авылында уләнчапкычы сатып алу;
- Кәүҗияк авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, өлкәннәр көне, 9 Май) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;
- район газетасы «Сарман»да некрологларны бастырып чыгару.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Кәүҗияк

авылы, Советская урамы, 66В йорт ; Тукай урамы 127А йорты адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кәүҗияк авыл җирлеге
Советы рәисе Ф.А.Хөснетдинов